**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3907**
**08.06.2021**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функция башкаруның административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясенең «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендге 2395-I номерлы Законының 5 статьясындагы 5 пункты, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»2 008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елны 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, Татарстан Республикасының «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Законы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функция башкаруның административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 8 июнендәге
3907 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функция башкаруның административ регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда административ процедураларның (административ гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Муниципаль контроль Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты функциясе булып тора.

1.2. Муниципаль контроль Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның вәкаләтле органы булып Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе (алга таба – муниципаль контроль органы) тора.

Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыралар.

1.3. Муниципаль контроль түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясенең «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Законы («РФ законнары җыентыгы», 06.03.1995, № 10, ст. 823 );

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (»РФ законнары җыентыгы», 07.01.2002, № 1 (1 өлеш), ст.1 );

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) («РФ законнары җыентыгы», 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

- «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон («РФ законнары җыентыгы», 08.05.2006, № 19, ст. 2060 );

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) («РФ законнары җыентыгы», 29.12.2008, № 52 (1 өлеш), ст. 6249 );

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары («РФ законнары җыентыгы», 12.07.2010, № 28, ст. 3706);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы («Российская газета», № 85, 14.05.2009);

- Татарстан Республикасының «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Законы («Республика Татарстан», № 14, 22.01.2000);

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы («Республика Татарстан», № 155-156, 03.08.2004);

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», № 235-237, 10.12.2005, № 249-250, 30.12.2005);

- Башкарма комитетның 2021 елның 12 гыйнварындагы 03-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе турында нигезләмә;

- әлеге регламент.

1.3.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр предметы булып Россия Федерациясенең «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Законы нигезендә билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдаланучылар (алга таба – тикшерү субъектлары) тарафыннан Россия Федерациясенең «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Законы, Татарстан Республикасының гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә билгеләнгән норматив хокукый актлары таләпләрен (алга таба — мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерү субъекты исеменнән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле вәкаләтләр бирелгән башка затлар (алга таба – вәкил) эш итә ала.

1.4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары:

- планлы, планнан тыш, документар, күчмә тикшерүләр, караулар үткәрергә;

- мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар, үзара бәйләнешсез тикшерүләр үткәрергә, тикшерү актлары төзергә;

- дәлилләнгән язма запрослар нигезендә, тикшерү субъектыннан тикшерүне үткәрү барышында кирәкле мәгълүматны һәм документларны сорарга һәм алырга (294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып);

- үткәрелә торган тикшерү предметына караган мәсьәләләрне тикшерү өчен экспертларны, эксперт оешмаларын билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

- гамәлдәге законнар нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

1.4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары бурычлы:

1) тикшерү субъектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

2) тикшерү үткәргәндә тикшерү субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясе законнарын үтәргә;

3) аның билгеләнешенә туры китереп, муниципаль контроль органы башлыгының аны үткәрү турында боерыгы нигезендә тикшерү үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын башкару вакытында, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, тикшерү үткәрү турында карар күчермәсен һәм 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы «а», «б» пунктчаларында каралган очракларда (әлеге регламентның 2.4.5 пунктында каралган очраклардан тыш), тикшерү үткәрүне килештерү турында документның күчермәсен күрсәткәндә үткәрергә;

5) тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы нигезендә, карамагында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан яисә дәүләт органнары буйсынуындагы органнардан яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алырга;

6) тикшерү үткәрелә башлау датасы буенча тикшерү субъектыннан документлар, мәгълүмат бирүне, шулай ук тикшерү субъектыннан яки аның вәкиленнән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлек нигезендә, карамагында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан яисә дәүләт органнары буйсынуындагы органнардан яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала һәм алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итмәскә;

7) тикшерү субъектына (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса - аның җитәкчесенә яки башка вазыйфаи затка) яки аның вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашырга һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

8) тикшерү субъектына (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса - аның җитәкчесенә яки башка вазыйфаи затка) яки аның тикшерү үткәргәндә катнашучы вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

9) тикшерү субъектын (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса - аның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затны) яки аның вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

10) тикшерү субъектын (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса - аның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затны) яки аның вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

11) шикаять бирелгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, тикшерү субъекты тарафыннан үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

12) әлеге регламентта билгеләнгән срокларны үтәргә;

13) тикшерү субъектының (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затның) яки аның вәкиленең үтенечe буенча, аны әлеге регламентның тикшерү үткәрүгә нигез булып торган нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшмәкәрдә (юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәргәндә) тикшерүләрне исәпкә алу журналы булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында язманы гамәлгә ашырырга;

15) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилгә яисә Татарстан Республикасында эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрдә катнашуда комачауламаска;

16) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары белән расланган тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә, мәгълүматларны тикшерүләрнең бердәм реестрына кертүне гамәлгә ашырырга;

17) 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка бурычларны гамәлгә ашырырга.

Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне үткәргәндә, вәкаләтле органның вазыйфаи затлары 294-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында билгеләнгән чикләүләрне үтәргә тиеш.

1.4.2. Тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары хокуклы түгел:

1) әгәр мондый таләпләр алар исеменнән әлеге вазыйфаи затлар эш итә торган муниципаль контроль органы вәкаләтләренә кермәсә, мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

1.1) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр үтәлешен, шулай ук аларны куллану мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләре үтәлешен тикшерергә;

1.2) мәҗбүри таләпләрнең һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) аны үткәргәндә җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктның «б» пунктчасында каралган нигез буенча мондый тикшерү үткәрү, шулай ук җир участоклары, җир асты участоклары милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир участоклары һәм җир асты участоклары арендаторларына тиешенчә хәбәр ителгән очракларда, җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тикшерү очракларыннан тыш;

3) әгәр алар тикшерү объектлары булып тормаса яки тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләре, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм житештерү мохите объектларын тикшерү пробалары бирүне таләп итәргә, шулай ук мондый документларның оригиналларын алырга;

4) илкүләм стандартлар, үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу кагыйдәләре һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлар яки алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү кагыйдәләре һәм методлары белән билгеләнгән нормадан артып киткән санда һәм билгеләнгән форма буенча күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турында беркетмәләр төземичә аларны тикшерүне, сынауны, үлчәүне үткәрү өчен

әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү пробаларын, продукция үрнәкләрен алырга;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга;

6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

7) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар хисабына контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашырырга;

8) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, физик заттан башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән исемлеккә кертелгән рөхсәт документларын да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүмат бирүне таләп итәргә;

9) тикшерү үткәрелә башлаган датага кадәр юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документлар, мәгълүмат бирүне таләп итәргә. Тикшерү үткәрү турында боерык яки приказ кабул ителгәннән соң, муниципаль контроль органы кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алырга хокуклы.

1.5. Муниципаль контроль чаралары гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.5.1. Тикшерү субъектлары түбәндәге хокукларга ия:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) вәкаләтле органнан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган һәм Россия Федерациясе законнарында бирү каралган мәгълүматны алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, аның белән, шулай ук вәкаләтле орган вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында тикшерү актында күрсәтергә;

4) вәкаләтле орган вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә тикшерү субъектының хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә;

5) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә;

6) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан, карамагында документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан яки дәүләт органнары буйсынуындагы органнардан яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

7) үз инициативасы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматны вәкаләтле органга тапшырырга.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүдә алар катнашкан очракта, Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең хокуклары һәм бурычлары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

1.5.2. Тикшерү үткәргәндә тикшерү субъектлары бурычлы:

1) юридик затлар җитәкчеләрнең, башка вазыйфаи затларның яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә; тикшерүнең башка субъектлары катнашырга яки муниципаль контроль предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкилләрнең булуын тәэмин итәргә тиеш;

2) күчмә тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән очракта, күчмә тикшерү үткәрә торган вәкаләтле органның вазыйфаи затларына, күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә;

3) күчмә тикшерүне үткәрүче вәкаләтле органның вазыйфаи затларының тикшерү субъектлары тарафыннан файдаланыла торган җир асты участокларына керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

4) вәкаләтле органның дәлилләнгән запросы буенча документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле документларны тапшырырга.

1.6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен тасвирлау

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып тора:

1) тикшерү субъектын тикшерү актын төзү (алга таба – тикшерү акты);

2) тикшерүне үткәрү барышында түбәндәге бозулар ачыкланган очракта:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә төзү һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә бирү;

- тикшерүне үткәрү барышында тикшерү субъекты тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, ачыкланган бозу билгеләре турында мәгълүматны күрсәтеп, тикшерү акты күчермәсен җирле әһәмияткә ия җир асты участокларына карата геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм җир асты байлыкларын саклау буенча региональ дәүләт күзәтчелеге органына җибәрү;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне тикшерү субъекты тарафыннан бозу ачыкланган очракта, материаллар әзерләү һәм тиешле контроль-күзәтчелек органнарына җибәрү;

3) тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турында акт төзү.

1.7. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның тулы исемлеге.

1.7.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга мөнәсәбәтле тикшерү субъектларыннан таләп ителергә мөмкин булган документларга түбәндәгеләр керә:

1) гражданның, җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең шәхесен таныклаучы документлар һәм аның вәкаләтләре.

2) күчмә тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән очракта, күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар.

1.7.2. Дәүләт органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларның һәм (яки) мәгълүматның тулы исемлеген түбәндәге документлар тәшкил итә:

1) күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) территориянең кадастр планы;

4) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар;
5) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар;
6) дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе турында мәгълүмат;
7) дәүләт су реестрындагы су объекты турында мәгълүматлар;
8) маркшейдер эшләрен башкаруга лицензияләр реестрыннан өземтә;
9) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр;
10) файдалы казылма төрләре буенча тау эшләрен үстерү планын яки схемасын килештерү турында карар күчермәсе;
11) гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару предприятиесен һәм гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмасын ликвидацияләү һәм консервацияләү турында акт.

Әгәр вәкаләтле орган карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса, яисә бу мәгълүматлар тикшерү субъекты тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тикшерү субъекты адресына, документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыруны таләп итеп, дәлилләнгән запрос җибәрә. Запроска тикшерү үткәрү турында приказның мөһер белән таныкланган күчермәсе теркәлә.

## II. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр

2.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирү

2.1.1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүматны алырга мөмкин:

1) административ-техник инспекция идарәсенә язмача мөрәҗәгать итү юлы белән.

Язмача мөрәҗәгатькә җавап гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә;

2) мәгълүматны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән;

3) телдән:

- муниципаль контроль чараларын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затлар белән телефон элемтәсе аша (тел.: 8(8552) 30-56-51 (административ-техник инспекция идарәсе));

- Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 234 кабинет адресы буенча административ-техник инспекция идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән;

Идарәнең эш режимы:
дүшәмбе-җомга – 8.00 дән 17.00 гә кадәр;
бәйрәм алды көннәре – 8.00 дән 16.00 гә кадәр;
төшке ял – 12.00 дән 13.00 гә кадәр;
ял көннәре – шимбә, якшәмбе.

2.2. Муниципаль контрольнең максатлары һәм бурычлары

2.2.1. Муниципаль контрольнең максаты булып җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнарны бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, шулай ук Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә

җир асты байлыкларыннан рациональ, нәтиҗәле файдалануга һәм шартнамә йөкләмәләре үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру тора.

2.2.2. Муниципаль контрольнең төп бурычлары булып юридик, вазыйфаи һәм физик затлар тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнарны үтәүне, билгеләнгән таләпләрне (нормаларны, кагыйдәләрне, нормативларны) үтәүне гамәлгә ашыру тора.

2.2.3. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль органы түбәндәгеләргә контрольне гамәлгә ашыра:

1) үз вакытында аренда шартнамәләрен төзү һәм җир участокларына, җир асты участокларына хокукларны дәүләт теркәвенә алу;

2) җир асты байлыкларыннан максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре буенча файдалану;

3) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән җир хокукын раслаучы документлардан башка, аларны үз белдеге белән файдалануга юл куймый торган тәртипне үтәү;

4) җирләрне, җир асты байлыкларын үз вакытында кире кайтару;

5) җирләрнең, җир асты байлыкларының торышы турында дөрес мәгълүматлар бирү;

6) аренда түләвен вакытында һәм дөрес түләү;

7) законнар нигезендә җир участокларында, җир асты участокларында билгеләнгән межалау, геодезия һәм башка махсус билгеләр булу һәм аларның сакланышы;

8) җир мөнәсәбәтләре, җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә бозуларны бетерү турындагы таләпләрне үтәү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнарны үтәү;

9) җирләрдән, җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча йөкләнгән бурычлар нигезендә башкалар.

2.3. Планлы тикшерүләр оештыру һәм үткәрү тәртибе

2.3.1. Планлы тикшерүне үткәрү предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнар нормаларын һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү тора.

2.3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да еш үткәрелми.

2.3.3. Планлы тикшерүләр, аның вәкаләтләренә туры китереп, муниципаль контроль органы тарафыннан эшләнә һәм раслана торган еллык планнар нигезендә үткәрелә.

2.3.4. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) исемнәре, эшчәнлеге планлы рәвештә тикшерелергә тиешле шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) урнашу урыннары яки шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекне фактта гамәлгә ашыру урыннары;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүне үткәрә башлау датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль органының исеме. Планлы тикшерү дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары белән берлектә үткәрелгәндә, мондый тикшерүдә катнаша торган барлык органнарның исемнәре күрсәтелә.

2.3.5. Планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планы, аны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, кызыксынган затларга җиткерелә.

2.3.6. Планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр муниципаль контроль органы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын билгеләнгән тәртиптә прокуратурага җибәрә.

2.3.7. Планлы тикшерүләр үткәрүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен нигезләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

2.3.8. Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, ул үткәрелә башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмый, планлы тикшерү үткәрелә башлау турында муниципаль контроль органы боерыгының күчермәсен, аны алу турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша һәм (яки) электрон документ әйләнеше аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы буенча җибәреп, муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан хәбәр ителә.

2.3.9. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерү үткәрүнең гомуми срогы елына кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артырга тиеш түгел.

2.3.10. Күчмә планлы тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү кирәклеге белән бәйле аерым очракларда, күчмә планлы тикшерүне үткәрү срогы муниципаль контроль органы башлыгы тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин кече предприятиеләргә карата егерме эш көненнән, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән артырга тиеш түгел.

2.4. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе

2.4.1. Планнан тыш тикшерү «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьсындагы 2 өлеше үткәрелә һәм планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлану;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тиешле планнан тыш тикшерүне үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт (килешү) бирү кагыйдәләрендә каралган очракта, муниципаль контроль органына юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) яки башка юридик әһәмияткә ия эшләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт (килешү) бирү турында гариза керү;

3) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар нәтиҗәләрен анализлау, муниципаль контроль органнарына түбәндәге фактлар турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматларны карап тикшерү яки алдан

тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органы вазыйфаи затының дәлилләгән күрсәтмәсе:

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү куркынычы янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

- Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе нигезендә чыгарылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесенең приказы (боерыгы).

2.4.2. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

2.4.3. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү әлеге регламентның 2.4.1 өлешенең 3 пунктындагы «а», «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган урын буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

2.4.4. Вәкаләтле орган башлыгы тарафыннан имзаланган килештерү турында гариза, планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карар имзаланган көнне, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган урын буенча прокуратура органына бирелә яисә тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрелә.

Килештерү турындагы гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар күчермәсе һәм тикшерү үткәрүгә нигез булган мәгълүматларны үз эченә алган документларның күчермәләре теркәлә.

2.4.5. Әгәр юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигез, мондый бозуларны кылган вакытта мәҗбүри таләпләрне бозуларны ачыклау торса, кичектергесез чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә, вәкаләтле орган, 24 сәгать эчендә прокуратура органнарына әлеге Регламентның 2.4.4 пунктында каралган документларны җибәрү юлы белән прокуратура органнарына контроль чаралар үткәрү турында хәбәр итеп, кичекмәстән планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүгә керешергә хокуклы.

2.4.6. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык муниципаль контроль органы башлыгы тарафыннан имзаланган көнне, аны үткәрүне килештерү максатларында, муниципаль контроль органы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гаризаны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган урын буенча прокуратура органына бирә яисә аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша яки электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Бу гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органы башлыгы боерыгының күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган мәгълүматларны үз эченә алган документлар теркәлә.

2.4.7. Планнан тыш күчмә тикшерү (үткәрү нигезләре әлеге регламентның 2.4.1 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш) үткәрелә башлаганчы кимендә егерме дүрт сәгать алдан, аны үткәрү турында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы тарафыннан, теләсә нинди уңайлы ысул белән, шул исәптән мондый адрес Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына бирелгән булса, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ ярдәмендә юридик затка, шәхси эшмәкәргә хәбәр ителә.

2.5. Документар тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе

2.5.1. Документар тикшерү муниципаль контроль органы карары нигезендә үткәрелә.

2.5.2. Документар тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан яки ике яки аннан күбрәк вазыйфаи зат составында контроль төркем тарафыннан, тикшерү үткәрү турында карарда билгеләнгән срокта үткәрелә.

2.5.3. Документар тикшерү барышында вәкаләтле вазыйфаи зат (контроль төркем) тарафыннан вәкаләтле орган карамагында булган һәм тикшерү субъекты тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирә торган документлар карап тикшерелә.

2.5.4. Вәкаләтле орган карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырган яки бу мәгълүматлар тикшерү субъекты тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, вазыйфаи зат документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыруны таләп итеп, тикшерү субъектына дәлилләнгән запрос (алга таба - запрос) проектын әзерли һәм аны имзалау өчен вәкаләтле орган башлыгына тапшыра.

2.5.5. Вәкаләтле орган башлыгы тарафыннан имзалаган запрос, тикшерүне үткәрү турындагы карарның мөһер белән таныкланган күчермәсен теркәп, тикшерү субъектына яки аның вәкиленә тапшырыла яисә тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша тикшерү субъекты яисә аның вәкиле адресына җибәрелә, шулай ук факсимиль элемтә яки электрон почта аша кабат җибәрә.

2.5.6. Запроста күрсәтелгән документлар вәкаләтле органга мөһер (булганда) белән һәм тикшерү субъекты яисә аның вәкиле имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Тикшерү субъекты яки аның вәкиле запроста күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар формасында тапшырырга хокуклы.

2.5.7. Документар тикшерү барышында, тикшерү субъекты тарафыннан бирелгән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган яки бу документлардагы мәгълүматларның вәкаләтле органда булган документлардагы һәм (яки) тикшерүне гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматларга туры килмәве ачыкланган очракта,

тикшерү субъектына бу хактагы мәгълүматны һәм хатны алган көннән башлап 10 эш көне эчендә язма рәвештә кирәкле аңлатмалар бирү таләбен үз эченә алган, тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрелә .

2.5.8. Вазыйфаи зат документар тикшерү барышында ачыкланган хаталар (каршылыклар, туры килмәүләр) буенча тикшерү субъектыннан алынган аңлатмаларны һәм элек тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны карап тикшерергә тиеш.

2.5.9. Әгәр документар тикшерү барышында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле орган карамагында булган документларындагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген таныкларга яисә тиешле контроль чара үткәрмичә, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләргә мөмкин булмаса, вазыйфаи зат (контроль төркем җитәкчесе) күчмә тикшерү үткәрүнең максатчан булуы (максатчан булмавы) турында дәлилләнгән тәкъдим белән, вәкаләтле орган башлыгы исеменә рәсми язу әзерли.

Күчмә тикшерү үткәргәндә тикшерү субъектыннан документар тикшерү үткәрү барышында аларга тапшырылган документлар һәм (яки) мәгълүмат бирүне таләп итү тыела.

2.6. Күчмә тикшерү үткәрү

2.6.1. Күчмә тикшерү муниципаль контроль органы карары нигезендә үткәрелә.

2.6.2. Күчмә тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан яки ике һәм аннан күбрәк вазыйфаи зат составында контроль төркем тарафыннан, тикшерү үткәрү турында карарда билгеләнгән срокта үткәрелә.

2.6.3. Тикшерү үткәрү урынына килгәч, вазыйфаи зат тикшерү субъектына яки аның вәкиленә хезмәт таныклыгын күрсәтә.

2.6.4. Тикшерү төркеме җитәкчесе (вазыйфаи зат) тикшерү үткәрү урынына килгәннән соң бурычлы:

1) тикшерү субъектын (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затны) яки аның вәкилен түбәндәгеләр белән таныштырырга:

- Тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органының карары;

- тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре;

- тикшерүне үткәрү максатлары, бурычлары һәм нигезләре, контроль чараларның төрләре һәм күләме, экспертлар, тикшерү үткәрүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләренең составы, аны үткәрү сроклары һәм шартлары;

2) тикшерү үткәрү турындагы карарның вәкаләтле вазыйфаи затның имзасы һәм муниципаль контроль органының мөһере белән таныкланган күчермәсен шәхсән имза куйдырып тапшырырга һәм бу уңайдан килеп туган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә.

294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешнең 2 пунктындагы «а», «б» пунктчаларында каралган планнан тыш күчмә тикшерү үткәрелгән очракта, тикшерү үткәрелә торган урынга килгән көнне контроль төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) тикшерү субъектына (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесенә яки башка вазыйфаи затка) яки аның вәкиленә, шәхсән имза куйдырып, әлеге регламентның 2.4.5 пунктында каралган очрактан тыш, мондый тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органнары карарының күчермәсен тапшыра.

Тикшерү субъектының (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затның) яки аның вәкиленең таләбе буенча тикшерү төркеме җитәкчесе (вазыйфаи зат) аны әлеге регламент белән таныштырырга, шулай ук үз вәкаләтләрен раслау максатларында вәкаләтле орган турында, шулай ук тикшерүне

үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

2.6.5. Тикшерү төркеме җитәкчесе (вазыйфаи зат) тикшерү субъекты (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесе яки башка вазыйфаи зат) яки аның вәкиле белән берлектә, тикшерү барышында үзара хезмәттәшлек итәчәк затлар даирәсен билгелиләр, тикшерү субъекты яки аның вәкиле алар белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш булган документлар исемлегенә, шулай ук тикшерүнең вакыт режимына (тикшерү субъектының гамәлдәге эш режимын исәпкә алып) төгәллек кертәләр.

2.6.6. Тикшерү барышында гамәлгә ашырыла:

1) җир участогын, җир асты участогын тикшерү;

2) фотога, видеога төшерү, инструменталь төшерү;

3) документларны һәм тапшырылган мәгълүматны анализлау;

4) кирәкле тикшерүләр, экспертизалар һәм 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка контроль чаралар үткәрү.

2.6.7. Тикшерү субъекты тарафыннан файдаланыла торган җир участогын, җир асты участогын тикшерү, тикшерү субъекты (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесе яки башка вазыйфаи зат) яки аның вәкиле үзе булганда, вазыйфаи зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җир участогын, җир асты участогын тикшерү барышында мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары ачыклаганда, алар фотога, видеога, инструменталь төшерү аша теркәлә, бу хакта тикшерү субъектына (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесенә яки башка вазыйфаи затка) яки аның вәкиленә телдән хәбәр ителә. Соңыннан, мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары тикшерү актында чагылдырыла.

2.6.8. Күчмә тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән очракта, күчмә тикшерү барышында документларны анализлау мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, вазыйфаи затлар, танышу өчен, күчмә тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле мәсьәләләр буенча тикшерү субъекты документларын таләп итәргә хокуклы.

Сорала торган документларны тапшыру исемлек буенча гамәлгә ашырыла.

2.6.9. Документлар (мәгълүмат) булмаган һәм (яки) аларны тапшыруга комачаулый торган башка хәлләр килеп чыккан очракта, тикшерү субъекты контроль төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) документларны тапшырмау сәбәпләре буенча язмача аңлатма бирергә хокуклы.

2.6.10. Тикшерү субъекты тикшерү үткәрү өчен кирәкле документларны тапшырудан баш тарткан очракта, тикшерү актында тиешле язу башкарыла.

2.6.11. Тикшерү субъекты (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесе яки башка вазыйфаи зат), аның вәкаләтле вәкиле булмау сәбәпле, яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлек фактта гамәлгә ашырылмау сәбәпле, яисә тикшерү субъектының (әгәр тикшерү субъекты булып юридик зат торса – аның җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затның), аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәрү мөмкин булмауга китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаган очракта, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты, тикшерүне үткәрү мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турында акт төзи. Бу очракта тиешле тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турындагы акт төзелгән көннән башлап 3 ай эчендә муниципаль контроль органы башлыгы, планлы тикшерүләрнең еллык планына кертмичә һәм тикшерү субъектына алдан хәбәр итмичә, мондый субъектка карата планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итә.

2.7. Тикшерүне оештыру тәртибе

Тикшерү муниципаль контроль органы башлыгы боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү бары тик боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

Боерык тикшерүне үткәрә торган муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан, бер үк вакытта хезмәт таныклыкларын күрсәтеп һәм имза куйдырып, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча, тикшерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар үз вәкаләтләрен раслаучы мәгълүмат бирергә тиеш.

Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11, 12 статьяларында каралган тәртиптә, документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

2.8. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

2.8.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан ике нөсхәдә акт төзелә (Тикшерү актының типовой формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә).

2.8.2. Тикшерү актына мәйданнарны үлчәү схемалары, фототаблицалар, кирәк булган очракта, җир участогын, җир асты участогын тикшерү акты, үткәрелгән экспертизалар бәяләмәсе, мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик зат, хезмәткәрләренең, шәхси эшмәкәрләрнең һәм физик затларның аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

2.8.3. Тикшерү акты турыдан-туры ул тәмамланганнан соң ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән бергә, тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында имза куйдырып, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тапшырыла. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, физик зат булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта. Акт почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән җибәрелә, ул делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

2.8.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән үлчәүләр, тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта төзелә һәм расписка буенча җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тапшырыла яисә аны тапшыру турында белдерү кәгазе (ул муниципаль контроль органы делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә) булган заказлы хат белән почта аша җибәрелә.

2.8.5. Урынга барып планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен, аны үткәрүне прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, тикшерү акты төзелгән көннән башлап биш эш көне эчендә, тикшерү актының күчермәсе тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрелә.

2.9. Тикшергәндә ачыкланган бозу фактларына карата муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан күрелә торган чаралар

2.9.1. Тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән вазыйфаи затлар үз вәкаләтләре чикләрендә бурычлы:

1) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча административ чаралар күрү өчен тикшерү материалларын дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына җибәрергә;

2) ачыкланган бозуларны бетерү өчен контроль чаралар күрергә.

## III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Административ процедуралар исемлеге

3.1.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерү үткәрү һәм аны үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү;

2) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар үткәрү;

3) юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү һәм аны үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү;

4) гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерү турында карар кабул итү үзенчәлекләре;

5) документар тикшерү үткәрү;

6) күчмә тикшерү үткәрү;

7) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

8) тикшерү үткәргәндә ачыкланган бозу фактларына карата чаралар күрү;

9) мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү.

3.4. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар оештыру һәм үткәрү

3.4.1. Муниципаль контроль органының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлеге таләп ителми торган контроль чараларга (алга таба – дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар) керә:

1) әлеге регламентның 3 бүлеге нигезендә, җир участоклары, җир асты участоклары территорияләрен тикшерү нигезендә планлы (рейд) караулар (тикшерүләр);

2) Интернет челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырганда мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү;

3) федераль закон нигезендә аны бирү бурычы (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән) мондый затларга йөкләнгән, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының, юридик затның һәм шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге һәм гамәлләре турында мәгълүматны анализлау ярдәмендә мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү;

4) федераль законнарда билгеләнгән контроль чараларның башка төрләре һәм формалары.

3.4.2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары үз компетенциясе чикләрендә, муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган мондый чараларны үткәрүгә йөкләмәләр нигезендә, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелә.

3.4.3. Әлеге регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм эчтәлеге, һәм муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары нәтиҗәләрен, шул исәптән планлы (рейд) караулар, тикшерүләр, тикшеренүләр, үлчәүләр, күзәтүләр нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе муниципаль контроль органы тарафыннан билгеләнә.

3.4.4. Әлеге регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән контроль чараларны үткәргәндә, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны бетерү буенча чаралар күрә, шулай ук, кирәк булганда, әлеге регламентның 2.4.1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча дәүләт хакимияте органын, җирле үзидарә органын, юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш тикшерүне билгеләү турында карар кабул итү өчен, муниципаль контроль органы җитәкчесенә язма рәвештә, ачыкланган бозулар турында мәгълүматны кертеп, дәлилләнгән белдерү юллый.

3.5. Тикшерү үткәргәндә вазыйфаи затларның җаваплылыгы

3.5.1. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## IV. Вәкаләтле органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

Судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә вәкаләтле органның, аның вазыйфаи затларының муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән (кылган) теләсә нинди карарларына һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелергә мөмкин.

Шикаять Башкарма комитет Җитәкчесенә юлланырга мөмкин.

Шикаять белән телдән мөрәҗәгать итәргә яки почта аша язмача мөрәҗәгать (шикаять), шул исәптән электрон почта адресына mky_ati@mail.ru электрон документ формасында җибәрергә мөмкин .

Шикаять кергән көнне теркәлергә тиеш һәм ул теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан карап тикшерелә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева